ГЛАВА КРАСНОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за. “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы
поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563)3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“19” октября 2020 г. — № 8

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Максим Пүчинкәсе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 06 нчы октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы Федераль законның 25.1,56 нчы статьясы нигезендә, Татарстан Республикасында “Җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Кызыл Тау авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставының 23 нче статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Максим Пүчинкәсе авылы Советская урамы, 6 нчы йорт каршында урнашкан территориядә 2020 елның 11 ноябре, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пучинкәсе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 1 нче кушымта нигезендә гражданнар җыены билгеләргә.
2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга

« Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пүчинкәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
- Максим Пүчинкәсе авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;

-Максим Пүчинкәсе авылында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру)

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитетына Максим Пүчинкәсе авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .
4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы: В.А. Гыйззәтуллина